КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 20 февраль г.Казань № 151

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2023 елларга Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалыгын, сәнәгать һәм башка оешмаларын газлаштыру буенча төбәк программасын раслау турында» 2019 ел, 30 декабрь, 1265 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2023 елларга Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалыгын, сәнәгать һәм башка оешмаларын газлаштыру буенча төбәк программасын раслау турында» 2019 ел, 30 декабрь, 1265 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 24 ноябрь, 1056 нчы; 2021 ел, 23 ноябрь, 1111 нче; 2022 ел, 18 май, 460 нчы; 2022 ел, 29 октябрь, 1151 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «2023» саннарын «2028» саннарына алмаштырырга;

1 пунктта «2023» саннарын «2028» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2019 – 2023 елларга Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалыгын, сәнәгать һәм башка оешмаларын газлаштыру буенча төбәк программасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

2. «Газпром трансгаз Казань» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә 2023 елның 1 мартына кадәр Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы адресына 2022 елга Татарстан Республикасын газлаштыру чаралары планының үтәлеше турында хисап кертүне тәкъдим итәргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин